Рәшит Бәшәр

0+

Нәни кунаклар



Рәшит Бәшәр

Нәни кунаклар

Балалар өчен хикәяләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2014

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Б90

Рәссамы *Татьяна Немцева*

Бәшәр, Р. Г.

Б90 Нәни кунаклар : балалар өчен хикәяләр / Рәшит Бәшәр ; [рәссамы Татьяна Немцева]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2014. — 39 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02765-6

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-02765-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2014
© Бәшәр Р. Г., 2014

ТӨШКЕ АШ

Шәһәрдән авылга, бабасы белән әбисе янына кунакка кайткан Ринат бүген соң уянды. Бабасының, иртән иртүк өйдән чыгышлый, «Озак йоклыйсың икән, улым. Мин болынга печән чабарга киттем. Төшке аш җиткәч, яныма килерсең» дигән сүзләрен дә малай әллә төшендә генә ишетте инде.

Шәһәрдә бит беркем дә иртә таңнан сикереп тормый. Ринат та менә иртә уянырга күнекмәгән. Авылга җәй саен кайта ул. Әммә йокыдан торулары һәрвакыт шулай кыен була. Өй бүрәнәләренә сеңгән нарат сагызы исе, алманыкы белән кушылып, борынны кытыклый-кытыклый, үпкәләргә агып кергәндә, бигрәк тә авыр инде. Эх, авыл һавасы...

Ринат күзләрен ачты. Киерелде. Юрган астыннан һич кенә дә чыгасы килми иде әле аның. Өйалдында сөт сорап йөрүче мәченең мияулаганы, ишегалдында тавыкларның кытаклаган тавышлары ишетелә башлады. Малай янә киерелде. Юрганы идәнгә шуып төшсә дә, мендәргә ябышып калган баш өскә күтәрелмәде.

Кинәт ишек шыгырдады. Ишектә ак яулыклы, зәңгәр күлмәкле әбисе күренде.

— Уяндыңмы, бәбкәм? Әйдә, ашарга тор. Табынны әзерләп куйдым инде.

Ринат, әбисенең йомшак тавышын ишетүгә, тәмле йокысын онытып, караваттан сикереп тә торды, юынырга да чапты. Майлы коймаклар ашап, баллы чәй эчкәннән соң, әбисе, тастымалга төрелгән кәстрүлне, ипи телемнәрен, чәй тутырылган термосны сумкага салып, аны оныгына тоттырды:

— Көн бик эссе, улым. Бабаң сусагандыр, ачыккандыр. Ризыкларны аңа тизрәк илтергә тырыш, бәбкәм.

Ринат аптырап ук калды. Аңа мондый җаваплы эш кушканнары юк иде әле. Малайның сөенече эченә сыймады. Ул баскычта яткан сандалиларын киде дә юлга чыкты.

Елга буена ул бик тиз төшеп җитте. Бабасы белән бергә аның бу юллардан йөргәне бар иде инде. Бүген исә ул үзе генә! Тик бабасын ничек кенә табарга соң? Аяк астында сикерешкән чикерткәләр дә бу сорауга җавап эзлиләр иде сыман. Малай шунда бабасы чапкан печән покосының күрше авылга таба сузылып киткәнен күреп алды. Үлән кибә дә башлаган икән. Чабылган печәнгә карап, бабасын табачак ул! Ринат чикерткәләргә күз кысты да елга яры буйлап китте.

Шулай бара торгач, кинәт таллар арасыннан авыл эте Акбай килеп чыкты. Ринатның дусты ул. Малай, бу ак койрыклы, кара борынлы этне күргән саен, аны тәмле әйберләр белән сыйлый иде.

Ринат, печән өстенә утырып, сумкадан ризыкларны алды. Тастымалны сүтеп, кәстрүлне ачып караса, анда дөге боткасы икән. Эткә бераз ботка бирим дип, кәстрүлгә тотынган гына иде, Акбай малайның кул астына ук кереп китте. Кәстрүл үләнгә капланды.

Күз ачып йомганчы Ринат, кәстрүлне күтәреп, ботканың бер өлешен саклап калды. Акбай исә дөге боткасын тәмләп ашый башлаган иде инде. Аңа карап, малай: «Нишләргә? Әллә өйгә кайтыргамы? Бабай бит бик ачыккандыр. Кояш әнә ничек кыздыра. Юк, мин кире кайтмыйм. Ботка аз булса да калды әле. Чәй дә бар», — дип уйлады.

Акбай, үләндәге дөге боткасын ашап бетереп, Ринатның кулын ялады, «Борчылма! Рәхмәт сиңа!» дигәндәй өреп тә алды. Дустының шулкадәр сөенгәнен күргәч, малайның да кәефе күтәрелде, һәм ул печән покосы буйлап алга атлады.

«Көн эссе. Эх! Киемнәрне салып, салкын суда чума-чума йөзәсе иде». Бу уйларны хуплагандай, елгада балыклар да сикерештеләр. Бабасы белән елга яры буйлап йөргәндә, Ринат балыкларга гел ипи ашата иде. Малай, үзе дә сизмәстән, сумкасыннан берничә ипи телемен чыгарып, ваклый-ваклый, су өстенә сипте. Балыкларга мондый күчтәнәч бик ошады: алар хәтта ныграк сикерешә башладылар. Кап-кара яр карлыгачы да ипи кисәген эләктереп очып китте.

Ринат, балыклар белән саубуллашып, юлын дәвам итте. «Кайда соң бабай? Беркая күренми».

Күктә кояш кыздыра...

Малай чәйле термосны кипкән иреннәренә китерде. «Юк! — Аңына килде Ринат. — Эчәргә ярамый. Бабай сусагандыр...» Ул, термосны сумкасына кире куеп, ял итәргә дип утырган җиреннән кузгалды.

Печән барган саен яшелләнде, сусылланды. Менә бу үлән яңарак кына чабылган. Бабасы шушы тирәдә генә булырга тиеш. Әнә ул! Әнә! Чалгысы да күренә!

— Бабай!

— Әү, улым!

Ринат бабасын табуына шундый сөенде, юлда булган маҗараларын онытып, сумканы бабасына сузды.

— Әби ботка җибәрде. Чәй дә бар! Ипи дә... — Ринат тотлыгып калды. Ботка кәстрүлдә бик аз бит. Бабай нәрсә дияр?

Бабасы, кәстрүлне ике аяк арасына куеп, капкачын ачты һәм аптырап калды. Аннары башын түбән игән Ринатка борылып карады.

— Ботканы үзең ашадыңмы әллә?

— Юк! Ул чирәмгә түгелде. Акбайны сыйлыйм дигән идем... Ипине елга балыкларына бирдем.

Бабасы кулына термосны алды һәм:

— Ботка ашагач, Акбай чәй дә эчтеме? — дип, хәйләкәр генә елмайды.

Башын аска игән малай борынын гына тартты.

Бабасы термосны оныгына кире бирде:

— Мә, эч, улым! Хәл керер. Көн бигрәк эссе.

— Рәхмәт, бабай!

— Улым, син дөрес эшләгәнсең! Бу киң дөньяда юмарт булырга кирәк безгә! Саранnарны яратмыйм мин.

Ринат үз колакларына ышанмады. Әллә бабасы аны мактый инде?

Бабасы савыт-сабаларны, тастымалга төреп, малайга сузды:

— Арыдым, улым. Җеп өзәрлек тә хәлем калмады. Әйдә, улым, син бу әйберләрне күтәр дә, без өйгә кайтыйк. Әбиеңнең өйдәге кәстрүлендә ботка калгандыр әле. Тәмле ботканы өйдә бергәләп ашарбыз!

НӘНИ КУНАКЛАР

Ишектән карга баткан өч малай килеп керде. Әби-бабасы белән исәнләшкәннән соң, Ралиф чаңгыларын стенага сөяде, Рузил чанасын коридор түренәрәк этеп куйды, ә Рамил кулындагы тимераякларын ишек төбенә атты. Гадәттә шау-гөр килгән ташбашлар бүген никтер бик тын иделәр. Әбисе белән бабасы моны шундук сизеп алды.

Малайлар бер сүз әйтмичә чишенделәр һәм, кулларын юар өчен, юыну бүлмәсенә кереп киттеләр. Аш өстәле янына килеп, урындыкларга утырышкач, бабалары малайларның аркаларыннан сөйде, хәлләрен сорашты. Аның күптәннән оныкларын күргәне юк иде. Әмма малайлар ачылып китмәделәр, бер-берсен күрмәмешкә салышып, тик үзалларына карап утырдылар.

Әбиләре шул арада чәчәк бизәкләре ясалган тәлинкәләргә кайнар пилмәннәр салды. Балаларның күңелләрен күрим дип, яшел тәмләткечләр дә сипте.

Әби-бабасы оныклары белән нәрсә булганын белергә бик теләсә дә, малайлар серне чишмәделәр, шулпага өрә-өрә, пилмәннәрен ашадылар. Аннары, рәхмәт әйтеп, өчесе өч бүлмәгә таралдылар.

Ралиф залда телевизор карарга утырды. Рузил, ял бүлмәсенә кереп, компьютер кабызды. Рамил коридорда туп тибә башлады. Бераздан «Гол!» дигән тавыш бүлмәләрне яңгыратып җибәрде, нәрсәдер идәнгә килеп төште. Бабалары аш бүлмәсеннән йөгереп чыкканда, туп аның колак яныннан ук сызгырып узды.

— Тот, бабай!

Бабасы идәндә тәгәрәгән тупны иелеп алды да:

— Улым, Рамил, тузан чыгармыйк. Үзеңә тынычрак бер шөгыль тап әле, — дип, аш бүлмәсенә кереп китте.

Рамилнең кәефе тагын да ныграк кырылды, ул зал ягына борылды. Ралиф бүлмәдә, онытылып, мультфильм карый иде. Рамил, диван читендә яткан пультны эләктереп, кара төймәгә басты. Мультфильмны футбол матчы алыштырды.

— Куй мультфильмны! — Ралиф, борынын мышкылдатып, пультка үрелде.

Рамил сикереп торды да матур гөл үсеп утырган

кечкенә өстәл янына килеп басты. Ралиф, пульт-ны алыйм дип, ялгыш Рамилгә бәрелде. Шунда көтелмәгән хәл булды: өстәлдәге гөл идәнгә килеп төште, келәмгә кап-кара балчык чәчелде. Бу — әбиләренең иң яраткан гөле иде.

Рамил тиз генә балчыкны чүлмәккә тутырырга кереште. Ралиф аңа булыша башлады. Рамил торды да:

— Әбинең чүлмәге синең аркада ватылды. Син гаепле! — дип кычкырып җибәрде. — Машиналарыңны да уйнарга бирмисең. Гел үзең генә уйныйсың!

Ралиф түзмәде:

— Син уенчыкларыңны ватасың. Бөтенесен ыргытасың, үз урынына куймыйсың, — диде.

Мондый тавышны ишетеп, Рузил, аннары әбисе белән бабасы залга чыктылар. Рузил, абыйларын дуслаштырырга теләп, яннарына якынлашты, әмма абыйлары аны күрмәделәр дә, һаман бәхәсләштеләр. Малайлар янына сиздермичә генә килгән әбиләре:

— Буялмагыз, балалар! Барыгыз, китап укыгыз! — дип, малайларны күрше бүлмәгә озатты. Кара балчыкны гөл савытына салды. Тузан суыргычны алып чыкты һәм келәмне чистартырга тотынды.

Бабалары малайлар янына күрше бүлмәгә керде.

— Балалар, нәрсә булды? Сөйләгез әле. Авызыгызга су капкандай тормагыз.

Ралиф алгарак чыкты да:

— Рамил миннән, уйнарга дип, машина сорады. Ә мин бирмәдем, чөнки ул үзенең уенчыкларын ватып бетерде. Хәзер инде...

— Аңлашылды, — дип туктатты аны бабасы. — Егетләр, алай ярамый. Туганнар бер-берсенә гел булыша, һәрвакыт ярдәм итә. Сиңа, Ралиф, машина белән ничек уйнарга кирәклеген Рамилгә күрсәтергә генә кирәк. Ул — бик аңлы малай. Туп белән әнә ничек яхшы уйный.

Рамилнең кәефе күтәрелеп китте. Ул алгарак чыкты да:

— Мин машина белән бик сак уйнармын, — дип, Ралифка кулын сузды.

Ралиф белән Рамил кул кысышты. Рузил, сөенеп, абыйларын кочаклап ук алды. Шулай дуслаштылар.

Бүлмәдән чыгып, малайлар әбиләренә булышты. Көлешә-көлешә, тәмләп чәй эчтеләр. Бүлмәләр нурланып киткәндәй булды.

Рузил белән бабасы шашка уйнады. Рамил белән Ралиф, диванга җәелеп яткан килеш кочаклашып, кино карады.

Кунаклар соң гына йокларга яттылар. Юрган астына кергәч:

— Әби! Иртәгә өчпочмак пешерерсең әле, яме! — дип йокыга киттеләр.

Әбиләре:

— Үзегезне тәртипле тотсагыз, өчпочмак та пешерермен, чия компоты да кайнатырмын! — дип, утларны сүндерде.

Бәләкәч

— Исәнме, бәләкәч! Син кемне көтәсең?

Рузил лифт ишеге каршында утырып торган сапсары көчеккә дәште. Кечкенә эт баласы, колакларын салындырган көе, башын иеп, лифтка керде дә ишек янындагы бер почмакка сыенды. Кап-кара күзләре белән малайга тутырып карады. Рузилнең әтисе

көчек белән малайга күз төшереп елмайды, аннары лифт төймәсенә басты. Ишекләр шыгырдап ябылдылар, һәм лифт кузгалып китте.

Рузил бу көчекне әле беренче мәртәбә күрә иде. Ул игътибар белән эт баласының кара борынына, ак койрыгына, сары тәпиләренә карады.

— Тәпиеңне аксаткансың бит, Бәләкәч. Ташка бәрдеңме? Авырткандыр инде, иеме?

Бәләкәч тәпиен ялап куйды.

— Мин дә, кичә йөгергәндә, аякны авырттырдым. Әнием аягыма массаж ясады, аяк төзәлде. Сиңа да массаж ясатырга кирәк. Бик рәхәт була ул, — дип, сүзен дәвам итте Рузил.

Эт баласы, башын күтәреп, Рузилгә карап алды.

— Минем әнием — табибә. Ул кичен генә кайта шул. Син безгә кунакка килсәң, әнием тәпиеңә массаж да ясар иде, аны бәйләп тә куяр иде.

Көчек төчкереп җибәрде.

Рузилнең әтисе:

— Әле син суык та тидергәнсең икән, — дип, эт баласы янына килеп чүгәләде һәм башыннан сыйпады.

Бәләкәч, алсу телен чыгарып, олы абыйның кулын ялап алды.

Рузил дә, әтисе кебек, көчек янына килеп чүгәләде.

— Аңа кайнар сөт эчәргә кирәк. Сөт эчеп, юрган астына кереп ятсаң тирлисең дә терeләсең, — диде һәм эт баласын сыйпый башлады.

Әтисе үз урынына китеп басса да, Рузил көчек янында калды.

— Син нигә шундый моңсу, бәләкәч? Бер сер әйтимме? Минем дә кәефем юк шул. Бик яхшы дустым чит шәһәргә күчеп китте. Туп белән уйнарга бер иптәшем дә калмады. Ә син туп белән уйный беләсеңме? Белмәсәң, мин өйрәтәм. Менә тәпиең төзәлер дә, без бергәләп уйнарбыз.

Лифт туктады, ишекләр ачылды. Алар унберенче катка менеп җиткәннәр иде. Көчек белән малай караңгы лифттан якты коридорга чыктылар.

Рузилнең әтисе, малайның җилкәсеннән сөеп:

— Бу — уникенче катта яшәүче Илдар исемле малайның көчеге. Алар безнең йортка күптән түгел генә күченделәр, — диде.

Рузил эт баласына карады һәм:

— Без, бәләкәч, бүген синең янга килербез. Әни синең тәпиеңә массаж ясар. Аннары ишегалдында уйнарбыз, яме? — диде.

Көчек сөенеченнән, ахры, коридорны яңгыратып өреп алды да, койрыгын болгый-болгый, баскыч буйлап уникенче катка йөгерде. Ул аксамый иде инде.

Рузил, яңа дус табуына сөенеп, әтисе белән бергә үз фатирларына юнәлде.

САБАНТУЙ БАТЫРЫ



Бүген Сабантуй!

Кояш Рузилне якты җылы нурлары белән сәламләп каршы алды. Тәрәзә каршында үскән каеннар, чаганнар да, ишегалдында чыр-чу килгән кошлар да — барысы малайны бәйрәм белән тәбрикләде.

Рузил алдан ук әзерләп куйган күмәч валчыкларын чәчәкле газонга сипте. Шуны гына көткәндәй, каяндыр өч күгәрчен очып килде һәм, «гөлдер-гөлдер-гөлдергү» дип, рәхмәтләрен укый-укый, валчыкларны чүпли башлады. Малай, күгәрченнәрнең ашаганын күреп, бик сөенде.

Рузил белән әбисе Сабантуй узачак болынга килеп җиткәндә, бәйрәм башланган иде инде. Малайның игътибарын озын колгада җилфердәп торган әләм җәлеп итте. Татарстан байрагы. Яшел, ак, кызыл төсләр кояш нурларында шундый матур булып уйныйлар, ирексездән ямь-яшел болын буйлап ап-ак ромашкалар, кып-кызыл сусыл җиләкләр җыярга китәрсең...

Ярышларның иң кызган чагы икән: кем йомырка салынган кашык кабып йөгерә, кем сулы чиләкләр тотып чаба, кем мәйданда көрәшә.

Рузил балалар мәйданчыгын күреп алды да шул якка таба тиз-тиз атлап китте. Мәйданчыктагы малайларның кайсысы машина, кайсысы туп тоткан. Кызлар рәхәтләнеп шоколад ашый. Әнә ике малай сулы мичкәдә балык тота. Балыклар кулдан ычкыналар да мичкәгә чумалар, алар артыннан малайларның башлары да суга кереп китә.

Бер ишегалдында яшәүче Зөләйха апасын күргәч, Рузил кояш кебек балкыды. Зөләйха апасы да малайны таныды. Өстәлдәге кәрзиннән яшькелт-кара роботны алды да Рузил янына килде.

— Исәнме, күрше! Озак йоклагансың бүген. Мә, Сабантуй истәлеге булсын! — дип, малайга робот сузды.

Рузилнең мондый роботы юк иде әле. Булганнары да ватылып беттеләр. Малай нишләргә дә белмәде. Менә робот. Кулыңны суз да ал. Сабантуйда алай эшләргә ярыймы соң? Ул як-ягына борылып карады. Рузилнең әнисе, ал эшләпәсен кигән нәни Алияне алдына утыртып, янындагы күрше

апага нидер сөйли иде. Әнә Марат. Чебен тимәс чер итәр бер елак малай ул. Тагын әнисенең итәгенә тагылган инде. Кулындагы туңдырмасы күлмәк изүенә аккан.

Рузил роботны Зөләйха апасына кире сузды һәм:

— Мә, апа! Мин бу роботны үзем көрәшеп алам, — диде.

Ул, кыю гына атлап, мәйданның уртасына узды.

Көрәштерүче абый аның каршына кап-кара чәчле таза гына бер малайны китереп бастырды. Рузил шикләнә башлады: «Әгәр җиңелсәм?»

Шунда ул биек колгага кунган күгәрченне күреп алды. Ишегалларында күмәч валчыкларын чүпләгән өч күгәрченне исенә төшерде. Рузилнең кәефе күтәрелеп китте, һәм ул, башын селкеп, борчулы уйларыннан тизрәк арынырга ашыкты.

«Юк, бирешергә ярамый! — Рузил сөлге белән таза малайның биленнән кысып алды да аны чирәмгә екты. — Көч бар икән бит. Эх, әни күрсә генә ярар иде!»

Таза малай сикереп торды, Рузилне биленнән алмакчы булды. Үзе мыш-мыш килә, аяк чалырга маташа. Рузилнең ачуы кабарды: таза малайны чирәмгә ничек итеп тәгәрәткәнен сизми дә калды. Көрәштерүче абый малайларны аякларына бастырды да җиңүченең кулын өскә күтәрде.

...Рузил әле капчык киеп тә йөгерде. Алдан килгән өчен, аңа футбол тубы бирделәр. Йомырка салынган кашык кабып чапты — машиналы булды...

Тәмам арып беткән Рузил әнисе алдына бүләкләрен китереп салгач, әнисе:

— Булдырдың, улым! — дип, малайның юешләнгән чәчләрен артка сыпырып куйды.

Малай сөенде. Сеңлесен күреп, уенчык машинаны Алиягә сузды.

Зөләйха апасы, килеп, малайның кулын кысты:

— Күрше! Кайда соң роботың?

Рузил яшькелт-кара роботны, бүләкләр арасыннан табып, һәммәсенә күрсәтте. Бу — аның көрәшеп җиңгән беренче бүләге.

— Менә бит, улым, син дә Сабантуй батыры булдың! — дип, әбисе малайны җилкәсеннән сөеп алды.

Ямь-яшел урманнар, ап-ак ромашкалы, кып-кызыл җиләкле аланнар алтынсу кояш нурларына күмелгән. Көн гаҗәеп матур. Мәйдандагы кешеләрнең күзләренә сөенеч тулган. Һәркем көлә, һәркем шатлана.

Рузилнең баш очыннан гына өч күгәрчен очып үтте. Алар да кулына уенчык робот тоткан малайны котлый иде.

АТ ЙӨРЕШЕ

Рузил караватыннан торды да стенадагы сәгатькә карады — вакытында уянган. Юыну бүлмәсенә кереп, битен, кулларын, муенын юды, тешләрен чистартты, көзге каршына басып, чәчен тарады. Көзгедән аңа түгәрәк йөзле, коңгырт күзле, саргылт чәчле, ап-ак тешле малай елмая иде. Рузил баш бармагын тырпайтты да: «Во!» — дип куйды. Әнисе пөхтә итеп үтүкләгән кара чалбарын, ак күлмәген киде. Абыйсы Рамил белән бергә чәй эчте.

Рамил, спорт киемнәрен алып, стадионга китәргә әзерләнде. Бүген анда яшь футболчылар уйный. Чыгып китешли, энесенә:

— Җиңеп кайт! — диде һәм кулын сузды.

Рузил Рамилнең учын шапылдатты:

— Син дә!

Ручкасын, яшел тышлы дәфтәрен кулына тотып, Рузил ишек төбенә килеп басты. Бүген ул шахмат

клубында үткәреләчәк ярышларда катнаша. Дүртенче разрядлы шахматчы булу өчен көрәшә. Узган ярышларда җыелган дүрт очкосы бар инде аның. Тагын бер уенда җиңсә, башкаларында отышсыз уйнау да җитә.

Шахмат клубы балалар белән шыгрым тулы иде. Икенче катка күтәрелделәр. Рузил стеналарга эленгән дипломнарга, пыяла шкафлардагы кубокларга кызыгып карап барды. Шундый кубок аның бүлмәсендә дә торса, ул бик бәхетле булыр иде. Ярыш узачак бүлмә янына килеп җиткәч, әтисе тәрәзә янындагы диванга утырып калды, Рузил, кыю гына атлап, яп-якты бүлмәгә килеп керде. Тренер абыйсының өстәлен яшь шахматчылар урап алган иде.

— Исәнмесез!

— Исәнме, Заһиров! — Тренер өстәлендә чәчелгән кәгазьләрне тәртипкә китерде дә: — Иванов! Заһиров! Өченче өстәл янына утырыгыз! — дип, урыныннан торды. — Син, Иванов, аклар белән уйныйсың, Заһиров — каралар белән!

Иванов Рузилдән бер башка озынрак иде, бәлки, шуңа күрәдер үзен эре тотты:

— Йокың туйдымы, егет? — дип, өстән аска карап алды.

— Әллә кайчан тордым инде мин, — дип үртәлде Рузил.

— Ничәнчедә укыйсың?

— Беренчедә.

— Фи! Әйтәм аны...

Иванов уенны пешка белән башлап җибәрде. Рузил дә ферзь алдындагы пешканы алга этте. Иванов филне алгарак чыгарып бастырды. Рузил эченнән генә: «Җиңел генә мат бирмәкче буласыңмы?» — дип уйлады һәм шундук саклык чарасын күрде: король алдындагы пешканы алга чыгарды. Иванов күзләрен челт-мелт йомгалады: «Каты чикләвек бугай бу!»

...Җиде яшьлек Рузил унике яшьлек Ивановны телсез калдырды. Менә сиңа мә! Иванов мат алды. Рузил көндәшенең кулын кысты һәм, тренер янына килеп:

— Абый! Мин оттым! — диде.

Тренер абыйсы борыны мышкылдаган Ивановны икенче өстәлгә күчерде, Заһировка бер очко өстәп язып куйды.

Рузил тагын ике уен уйнады. Почык борынлы Сәлимне ун йөрүдә җиңгәч, Рузил өстәле янына күбәләк сыман алсу бантиклар таккан Алсуны утырттылар. Бигрәк чая кыз булып чыкты ул. Иреннәрен бөрештереп, бантиклары белән уйнап утыргандай итте дә, өч-дүрт тапкыр шах биргәннән соң:

— Мат! — дип, шоколад исе килгән учын малайга сузды.

Кызга оттыру Рузилнең кәефен кырса да, ул әллә ни аптырап тормады: дүртенче разряд алу өчен аның очколары җитә иде инде.

Тренер абыйсы, Рузил янына килеп:

— Молодец, Заһиров! Алты очкоң җыелды. Дүртенче разрядлы шахматчы булдың! — дип котлады.

Малайның түбәсе күккә тиде.

— Киләсе атнада өченче разрядны алу өчен уйный башларсың!

— Мин бүген үк уйныйм, абый...

Тренер малайга сынап карады:

— Арыдың, егет. Бүгенгә җитәр.

— Юк. Бүген уйныйм.

Тренер малайның үҗәтлеген белә иде инде. Буе орчык кына булса да, тоткан җиреннән өзә торган

малай бу. Тренер Рузилне күрше бүлмәгә алып керде һәм:

— Ярар, уйна! Бу юлы йөрешләреңне дәфтәреңә язарга туры киләчәк. Көндәшеңнең йөрешләрен дә теркәп бар. Өеңдә һәр уеныңны кабат уйнап, тикшереп чыгарсың. Кайда нинди хата җибәрүеңне ачыкларсың... — диде һәм каршы өстәл янында басып торучы озын малайга дәште: — Илдар, кил монда! Заһиров белән уйна!

Илдар белән Рузил уртак нәтиҗәгә уйнадылар. Рузилнең булган очколарына тагын ярты очко өстәлде.

Коридорга чыгып, бераз ял итеп кергәч, Рузилнең өстәле янына Саша килеп утырды.

Узган ярышларда Рузил Сашаны ике тапкыр откан иде инде, шуңа күрә ул артык борчылмады. Саша кул сузгач, Рузил дә аңа кул бирде. Уен башланып китте.

Саша ферзь каршындагы пешканы алга этте. Рузил дә шул ук йөрешне кабатлады. Саша ферзьне алга чыгарды. Рузил, офицер каршындагы пешканы алга этеп, офицер өчен уен кырына чыгу юлын ачты...

Уен озакка сузылды. Уен кыры төрле-төрле фигуралар белән чуарланды. Әле Рузил, әле Саша шах бирде. Өстәл өсте уеннан чыккан пешкалар, офицер, атлар белән тулды. Озак тартыштылар. Кинәт Саша мат куйды. Көтелмәгән йөрештән Рузил кечерәеп калды, ни әйтергә белмәде. Саша болай уйнар дип уйламаган иде ул. «Барыбер җиңәрмен!» дип башланган уен җиңелү белән тәмамланды.

Тренер абыйсы Рузилне ишек төбенә хәтле озата чыкты. Аның әтисенә:

— Тырыш егет! Булдыра! — дип елмайды да Рузилнең кулын кысты. — Разрядлы шахматчы булуың белән котлыйм!

Әтисе дә:

— Молодец, улым! — дип, малайның чәченнән йомшак кына итеп сыйпады.

Мактасалар да, Рузилнең кәефе кырылган иде. Соңгы уен, дөресрәге, оттыру аңа тынычлык бирмәде. Ничек булды соң бу?

Өйгә кайтып ял иткәч, Рузил белән әтисе кабат шахмат уйнарга утырдылар. Иң элек малай мат алган соңгы уенның йөрешләрен тикшерде. Әтисе сары чәчле Саша булып уйнады. Дәфтәргә теркәлеп

барган һәр йөреш кабат йөрелде. Ниһаять, Рузил җиңелү сәбәбен тапты: ул ат белән ялгыш йөреш ясаган.

— Ашыкканмын. Сулга китәсе урынга уңга киткәнмен, әти. Сулга киткән булсам... Эх!

Рузил төшендә дә шахматлар күрде. Елгада су эчкән атка атланып маташа, имеш. Ат кешни икән. Малай, куе ялга ябышып, атның сыртына ук менә һәм аны сулга бормакчы була, ә ат, киреләнеп, уңга каера. Малай — сулга, ат — уңга...

— Нигә киреләнәсең? — дип сорый малай.

Ә ат, кешни-кешни:

— Масайдың бит, егет, үзеңне җиңмәсләр дип уйладың, көндәшеңә өстән карый башладың. Шуңа күрә мин, сине тыңламыйча, уңга киттем, — ди икән.

— Мин башка алай эшләмәм. Һәр уенга әзерләнермен, һәр уенчыны хөрмәт итәрмен! — дип ялварды малай.

— Алай булса, мин һәм башка фигуралар да синең боерыкларыңны үтәргә әзер. Сиңа әле бик күп уеннар уйнарга туры киләчәк, Рузил! Чемпион булырсың! Әмма биргән сүзеңне онытма. Уеннарга

яхшы әзерлән, көндәшләреңне хөрмәт ит! — Шулай диде дә ат күздән югалды.

Рузил ат кешнәгән тавышка уянып китте. Әтисе белән абыйсы телевизор карап утыралар иде. Рузил телевизорга карады. Экранда, башларын чөеп кешни-кешни, атлар чабалар икән.

Малай төшендә күргән атның сүзләрен исенә төшерде. Ат аңа: «Чемпион булачаксың!» — дип әйтте ләбаса. Аның өчен ай-һай күп тырышасы бар әле. Масаерга гына ярамый. Рузил тылсымлы атка биргән вәгъдәсен тагын кабатлады һәм, ниһаять, тынычланып йоклап китте.

ЭЧТӘЛЕК

Төшке аш

3

Нәни кунаклар

10

Бәләкәч

17

Сабантуй батыры

22

Ат йөреше

29

Литературно-художественное издание

Для детей дошкольного и младшего школьного возраста

Башар Рашит
(**Башаров** Рашит Гафарович)

МАЛЫШИ В ГОСТЯХ

Казань. Татарское книжное издательство. 2014

Әдәби-нәфис басма

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Бәшәр Рәшит
(**Бәшәров** Рәшит Гафар улы)

НӘНИ КУНАКЛАР

Мөхәррире *Г. К. Мансурова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А. С. Газизҗанова*
Корректоры *Г. М. Хәбибуллина*

0+ Знак информационной продукции
согласно ФЗ от 29.12.2010 г. №436—ФЗ.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.09.2014. Форматы 70×90 1/16.
Шартлы басма табагы 2,9. Тиражы 3500 д. Заказ А-2416.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru e-mail: info@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете. Тел.: (843) 519-45-13.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

9 785298 027656

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ